СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.09.2018 с. Большие Мεми № 44-203

## Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 п. 1 п. , Югары Ослан муниципаль районының Олы Мәми авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы?:

- Олы Мәми авылында Яшьләр һәм Елга аръягы урамнарына өлешчә вак таш түшәү;
- Заборная Поляна авылында урамнарны яктырту системасын ремонтлау

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина